| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.09.2025 г.Казань № 151-2/соц-2025

«Социаль мәшгульлекне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә тариф билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023-2026 елларда «Аутистик спектр тайпылышлары һәм башка менталь тайпылышлары булган инвалидларның социаль мәшгульлеген тәэмин итүгә ярдәм оештыру» сынау проектын гамәлгә ашыру турында» 2025 елның 5 июлендәге 486 номерлы, «2025 елга «Социаль мәшгульлекне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Социаль мәшгульлекне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүгә җан башына исәпләнгән норматив чыгымнарны һәм «Социаль мәшгульлекне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүгә җан башына исәпләнгән финанслау нормативын исәпләү тәртибен раслау турында» 2025 елның 16 августындагы 612 номерлы карарлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2025 елның 3 сентябрендәге 15-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә «Социаль мәшгульлекне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүгә тариф билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф карар үз көченә кергән көннән алып 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С. Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
03.09.2025 № 151-2/соц-2025
карарына кушымта

«Социаль мәшгульлекне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә тариф

| № | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Тариф |
|---|---|---|---|
| 1. | «Социаль мәшгульлекне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү | сум/сәгать | 71,7 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге